КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 февраль г.Казань № 106

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 24 май, 349 нчы; 2015 ел, 30 март, 198 нче; 2016 ел, 24 март, 165 нче; 2017 ел, 22 апрель, 238 нче; 2018 ел, 9 апрель, 224 нче; 2018 ел, 10 сентябрь, 766 нчы; 2019 ел, 22 март, 214 нче, 2019 ел, 29 май, 455 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны | Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме |

| | |
|---|---|
| финанслау күләмнәре | 14 511,95 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 1 016,48 млн.сум;<br>2015 ел – 3 376,21 млн.сум;<br>2016 ел – 1 886,84 млн.сум;<br>2017 ел – 1 415,82 млн.сум;<br>2018 ел – 3 734,22 млн.сум;<br>2019 ел – 2 331,99 млн.сум;<br>2020 ел – 260,38 млн.сум;<br>2021 ел – 242,41 млн.сум;<br>2022 ел – 247,6 млн.сум.<br>Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган финанслау күләме Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк»; |

Программаның I бүлегендәге 1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү (алга таба – КУЭ) кече һәм урта бизнесны үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы (алга таба – 209-ФЗ номерлы Закон) Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары тарафыннан КУЭ субъектларына арендага, шул исәптән ташламалы шартларда да, дәүләт мөлкәте исемлекләрен раслауны күздә тота.

КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү дәүләт мөлкәтен хуҗалык әйләнешенә җәлеп итүгә, кече һәм урта бизнесның мөлкәти базасын ныгытуга ярдәм итәчәк, шул ук вакытта арендалы түләүләр керү, шулай ук арендаторларның мөлкәтен сатып алу хисабына бюджет керемен арттырачак.

Программаның максатларының берсе – Татарстан Республикасы территориясендә кече һәм урта бизнесны үстерүне стимуллаштыру, шул исәптән казна объектларының мөлкәти потенциалын куллану исәбенә дә.

КУЭ мөлкәти ярдәм күрсәтү өлешендә әлеге Программаның бурычлары булып тора:

1. КУЭ субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегендә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте санын арттыру (алга таба – Исемлек).

2. Мөлкәтне арендага бирү буенча ташламалы тәртипне камилләштерү.

3. Мөлкәтне милеккә (файдалануга) бирү процедураларының гадиләшүе һәм үтә күренмәлелеген арттыру.

Татарстан Республикасында КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү түбәндәге принципларда гамәлгә ашырыла:

мәгълүмати ачыклык (транспарентлык): «Интернет» мәгълүмат-телекоммуни-

кация челтәрендәге рәсми сайтларда Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертелгән мөлкәт турында, Исемлегенә кертелгән мөлкәт турында, мөлкәти ярдәм күрсәтүне җайга салучы хокукый актлар турында мәгълүмат урнаштыру;

КУЭ субъектларының милек ярдәме алуга тигез үтеп керүе: КУЭ субъектларына милеккә ия булу һәм (яки) файдалануга бирү турындагы карарларны әзерләү, кабул итү һәм үтәү барышында көндәшлекне яклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәү;

дәүләт (муниципаль) милкенә кергән, яңа ачыкланган, шулай ук кулланылмый торган, нәтиҗәсез файдаланыла торган яки билгеләнеше буенча кулланылмый торган мөлкәт исемлегенә кертү өстенлеге, дәүләт бурычларын хәл итү өчен дәүләт хакимияте органнарын яки дәүләт оешмаларын урнаштыру өчен кирәк булган очраклардан тыш;

КУЭ субъектларының арендаланган дәүләт мөлкәтен сатып алуга өстенлекле хокукы тормышка ашырылган мөлкәтне алыштыру максаты белән Исемлекне ел саен яңа объектлар белән тулыландыру;

Исемлеккә кертелгән мөлкәткә ихтыяҗ: КУЭ субъектларына озак сроклы арендага бирелә алмый торган мөлкәт исемлегенә кертелмәү яисә алар тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару өчен файдаланыла алмый.»;

Программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Төп максат, бурычлар, чаралар, программаның көтелгән соңгы нәтиҗәләрен тасвирлау, аны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары

Программаның максаты – Татарстан Республикасы дәүләт милке белән идарә итүнең максималь нәтиҗәлелеген, аның керемлелеген һәм сакланышын тәэмин итү.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителергә тиеш:

1. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен тулысынча һәм дөрес исәпкә алуны тәэмин итү.

2. Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше булган дәүләт предприятиеләре һәм акционерлык җәмгыятьләре белән нәтиҗәле идарә итүне, аларның хокуксызлыгын профилактикалауны тәэмин итү.

3. Дәүләт милке һәм җир кишәрлекләре белән нәтиҗәле эш итүне һәм аларны, шул исәптән баланс тотучы оешмалар тарафыннан куллануны тәэмин итү.

4. Дәүләт милке составын һәм структурасын оптимальләштерү.

5. Гражданнарның гамәлдәге законнар белән билгеләнгән мөлкәт хокукларын тәэмин итүне оештыру.

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен тулысынча һәм дөрес исәпкә алуны тәэмин итү» бурычы кысаларында дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре мөлкәтенең составы турындагы мәгълүматларны Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрында актуальләштерүне тәэмин итәргә кирәк.

«Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше булган дәүләт предприятиеләре һәм акционерлык җәмгыятьләре белән нәтиҗәле идарә итүне

тәэмин итү, аларның нәтиҗәсезлеген профилактикалау» бурычы кысаларында түбәндәге чараларны үтәү зарур:

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре һәм устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше 50 дән 100 гә кадәр процент булган акционерлык җәмгыятьләре эшчәнлеген икътисадый мониторинглауны гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән хезмәт шартнамәләре шартларын үтәүне тикшереп торуны көчәйтү.

«Дәүләт милке һәм җир кишәрлекләре белән нәтиҗәле эш итүне һәм аларны, шул исәптән баланс тотучы оешмалар тарафыннан куллануны тәэмин итү» бурычы кысаларында түбәндәге чараларны үтәү зарур:

дәүләт милкен һәм җир кишәрлекләреннән файдаланудан кергән табыш өлешендә бюджет йөкләмәсен үтәүне тәэмин итү;

оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен файдалану буенча тикшерү чараларын үткәрү;

«Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү;

«Матди тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү;

«Торак фонды белән идарә итү департаменты» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү;

бәяләү эшчәнлеге белән бәйле социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтү;

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре файдалануында булган җир кишәрлекләреннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын рәсмиләштерүне тәэмин итү;

җирләрне бер категориядән икенче категориягә күчерү белән аларны категорияләргә кертүне тәэмин итү (Татарстан Республикасы милкендәге җирләргә, шулай ук муниципаль һәм шәхси милектә булган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә карата);

җир төзелеше эшләрен оештыру һәм үткәрүне тәэмин итү;

«Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү;

«Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасы чикләрен урнаштыру һәм билгеләү буенча чараларны үткәрүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен документлар әзерләү чараларын үткәрүне тәэмин итү;

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән дәүләт милке исемлегендә ел саен мөлкәт объектлары санының кимендә 10% ка артуы;

гомуми практика табиблары офислары өчен биналар сатып алу.

«Дәүләт милке составын һәм структурасын оптимальләштерү» бурычы кысаларында түбәндәге чараларны үтәү зарур:

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) үтәү;

дәүләт катнашында оешмаларның устав капиталларына инвестицияләү;

Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр хисабына Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренең устав фондын аларның эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында арттыру;

мөлкәт һәм җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт милкенә сатып алу.

«Гамәлдәге законнар белән билгеләнгән гражданнарның мөлкәт хокукларын тәэмин итүне оештыру» бурычы кысаларында Татарстан Республикасының күп балалы гаиләләренә җир кишәрлекләре бирү эшен оештыру буенча чараларны үтәү зарур.

Тулаем алганда, күрсәтелгән бурычлар һәм чаралар Татарстан Республикасы дәүләт милке белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән.

2022 елга программа чараларын гамәлгә ашыру барышында түбәндәге төп нәтиҗәләргә ирешеләчәк:

дәүләт милкен һәм җир кишәрлекләреннән файдаланудан кергән табыш өлешендә бюджет йөкләмәсен үтәү – 100 процент;

Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрында булган дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре санында Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрында актуальләштерелгән дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре өлеше (банкрот оешмаларны һәм бетерелүдә булган оешмаларны исәпкә алмыйча) – 100 процент;

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең гомуми санында Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен куллануны тикшерү үткәрелгән Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре өлеше – 100%;

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрендә булган җир кишәрлекләренең гомуми санында Татарстан Республикасы милкенә теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрендә булган җир кишәрлекләре өлеше – 99 процент;

җир төзелеше эшләрен оештыру һәм үткәрүне тәэмин итү буенча чараларның гомуми санында җир төзелеше эшләрен оештыру һәм үткәрүне тәэмин итү буенча башкарылган чаралар өлеше – 100 процент;

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән дәүләт милке исемлегендәге мөлкәт объектлары саны – 107 берәмлек;

үзгәртеп коруга планлаштырылган Татарстан Республикасы предприятиеләре санында Татарстан Республикасының үзгәртеп корылган предприятиеләр өлеше (акционирлау, бетерү, үзгәртеп кору процедуралары белән) – 100 процент;

кертү өчен планлаштырылган инвестицияләр күләменә карата дәүләт катнашында оешмаларның устав капиталларына кертелгән инвестицияләр күләме өлеше – 100 процент;

хисап елы башына җир кишәрлеге алу өчен исәпкә баскан Татарстан Республикасының күп балалы гаиләләре арасында бушлай җир кишәрлекләре алган Татарстан Республикасының күп балалы гаиләләре өлеше – 69 процент.

Максат, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук Программада

каралган чараларны финанслау күләме аңа кушымтада күрсәтелгән.

Программаны тормышка ашыру вакыты: 2014-2022 еллар.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 14 511,95 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча бүлеп:

2014 ел – 1 016,48 млн.сум;
2015 ел – 3 376,21 млн.сум;
2016 ел – 1 886,84 млн.сум;
2017 ел – 1 415,82 млн.сум;
2018 ел – 3 734,22 млн.сум;
2019 ел – 2 331,99 млн.сум;
2020 ел – 260,38 млн.сум;
2021 ел – 242,41 млн.сум;
2022 ел – 247,6 млн.сум.

Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган финанслау күләме Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк.»;

Программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасына кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 13 февраль, 106 нчы карары редакциясендә)

## «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасының максаты, бурычлары, аның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Чаралары үтәү вакытлары | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән финанслау, млн.сум | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
| Максат: Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең максималь дәрәҗәдә нәтиҗәле, керемле булуын һәм саклanышын тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Бурыч: Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен тулы һәм дөрес исәпкә алуны тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрында дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре мөлкәте составы турындагы мәгълүматларны актуальләштерү | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Мөлкәт министрлыгы) | 2014 – 2022 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренең һәм дәүләт учреждениеләренең гомуми санында (банкротлар дип танылган һәм бетерелү процессында булган оешмаларны исәпкә алмыйча) мөлкәтләре составы турындагы мәгълүматлары актуальләштерелгән Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 13,35 | 9,49 | 12,12 | 11,22 | 13,75 | 15,72 | 11,66 | 11,92 | 12,09 |
| Бурыч: Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше булган акционерлар җәмгыятьләре һәм дәүләт предприятиеләре белән нәтиҗәле идарә итүне, аларның бөлгенлеккә төшүен профилактикалауны тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше 50 проценттан 100 процентка кадәр булган акционерлар җәмгыятьләре һәм Татарстан | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше 50 проценттан 100 процентка кадәр булган акционерлар җәмгыятьләренең һәм Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренең гомуми санында финанс-хуҗалык эшчәнлегенә ТР Мөлкәт мини- | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 14,02 | 9,96 | 12,73 | 11,78 | 14,44 | 16,51 | 12,24 | 12,51 | 12,69 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре эшчәнлегенә икътисадый мониторингны гамәлгә ашыру | | | стрлыгы тарафыннан анализ ясалган устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше 50 проценттан 100 процентка кадәр булган акционерлар җәмгыятьләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт шартнамәләре шартларының үтәлешен тикшерүдә тотуны көчәйтү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт шартнамәләренең гомуми санында Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән һәм шартлары 100 процентка үтәлгән хезмәт шартнамәләре өлеше, процент | 70 | 73 | 75 | 78 | 80 | 82 | 83 | 85 | 85 | 85 | 6,01 | 4,27 | 5,45 | 5,05 | 6,19 | 7,07 | 5,25 | 5,36 | 5,44 |
| Бурыч: Дәүләт мөлкәте һәм җир кишәрлекләре белән нәтиҗәле эш итүне һәм алардан файдалануны (шул исәптән баланста тотучы оешмалар тарафыннан) тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен реализацияләүдән һәм файдаланудан алынган керемнәр өлешендә бюджет йөкләмәсе үтәлешен тәэмин итү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | Дәүләт мөлкәтен һәм җир кишәрлекләрен реализацияләүдән һәм файдаланудан алынган керемнәр өлешендә бюджет йөкләмәсен үтәү, процент | 110 | 101,55 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 66,19 | 47,03 | 60,07 | 55,63 | 68,13 | 66,78 | 49,53 | 50,62 | 51,35 |
| Оешмаларның Татарстан Республикасы мөлкәтеннән файдалануын тикшерү чаралары үткәрү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре-нең гомуми санында Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән файдалануга тикшерү үткәрелгән Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре өлеше, процент | 50 | 57 | 64 | 67 | 78 | 85 | 92 | 100 | 100 | 100 | 11,35 | 8,06 | 10,3 | 9,55 | 11,68 | 13,36 | 9,91 | 10,12 | 10,27 |
| «Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | Татарстан Республикасы милкенә теркәлергә планлаштырылган күчемсез мөлкәт объектлары санына карата Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алу үткәрелгән күчемсез мөлкәт объектлары өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 5,5 | 5,5 | 6,03 | 6,87 | 10,17 | 11,01 | 11,91 | 12,16 | 12,44 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Матди тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | «Матди тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә беркетелгән транспорт чараларының гомуми санына карата рейска чыгу тәэмин ителгән транспорт чаралары саны өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 57,75 | 67,22 | 77,44 | 78,46 | 74,21 | 74,97 | 76,68 | 78,58 | 80,65 |
| «Торак фонды белән идарә итү департаменты» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2017 – 2022 еллар. | «Торак фонды белән идарә итү департаменты» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торак урыннарның гомуми санына карата наемга алучылары белән (социаль / махсуслаштырылган торак фондының) наем шартнамәләре төзелгән торак урыннар өлеше, процент | - | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | 2,0 | 2,23 | 2,31 | 2,33 | 2,4 | 2,48 |
| Бәяләү эшчәнлегенә бәйле социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәмен гамәлгә ашыру | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2019 – 2022 еллар | Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары сораулары буенча бәяләү эшчәнлеге өлкәсендә эксперт бәяләмәләре саны | - | - | - | - | - | - | 70 | 110 | 150 | 180 | - | - | - | - | - | 2,55 | * | * | * |
| Җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милке хокукларын теркәүне тәэмин итү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрендәге җир кишәрлекләренең гомуми санында Татарстан Республикасы милкенә теркәлгән, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрендә булган җир кишәрлекләре өлеше, процент | 90 | 95 | 98 | 99 | 99 | 99 | 99 | 99 | 99 | 99 | 4,73 | 3,36 | 4,29 | 3,97 | 4,87 | 5,57 | 4,13 | 4,22 | 4,28 |
| Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре файдалануындагы җир кишәрлекләреннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын рәсмиләштерүне тәэмин итү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | ТР Мөлкәт министрлыгы боерыклары нигезендә | 97,2 | 98,3 | 99,2 | 99,5 | 99,5 | 99,5 | 99,5 | 99,5 | 99,5 | 99,5 | 4,73 | 3,36 | 4,29 | 3,97 | 4,87 | 5,57 | 4,13 | 4,22 | 4,28 |
| Татарстан Республикасы дәүләт учрежде- | | | | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 7,56 | 5,37 | 6,87 | 6,36 | 7,79 | 8,9 | 6,6 | 6,75 | 6,85 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ниеләре файдалануындагы җир кишәрлекләренең гомуми санында даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукы рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Җирдә төзү эшләрен үткәрүне оештыру һәм тәэмин итү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | Җирдә төзү эшләрен үткәрүне оештыру һәм тәэмин итү чараларының гомуми санында җирдә төзү эшләрен үткәрүне оештыру һәм тәэмин итү буенча башкарылган чаралар өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 10,38 | 31,15 | 29,71 | 0,29 | 0,09 | 0,61 | * | * | * |
| «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2017 – 2022 еллар | Җир кишәрлекләренә һәм башка күчемсез объектларга дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү чараларының гомуми санында җир кишәрлекләренә һәм башка күчемсез объектларга дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү буенча башкарылган чаралар өлеше, процент | - | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | 12,88 | 18,51 | 18,36 | 18,51 | 19,12 | 19,76 |
| «Татарстан Республикасының Киңлек мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2019 – 2022 еллар | Мәгълүмат ресурсларын һәм мәгълүмат базаларын алып бару чараларының гомуми санында мәгълүмат ресурсларын һәм мәгълүмат базаларын алып бару буенча башкарылган чаралар өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | 18,47 | 10,63 | 11,0 | 11,39 |
| Гомуми практика табиблары өчен офис урыннары сатып алу | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 ел | Сатып алырга планлаштырылган урыннарның гомуми санында гомуми практика табиблары офислары өчен сатып алынган урыннар өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | 33,5 | * | * | * |
| Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына кертү өчен | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2019 – 2022 еллар | Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак пунктлар чикләре турында белешмәләр кертү өчен документлар әзерләү буенча башкарылган чараларның гомуми күләме, Татарстан Республикасы | - | - | - | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | 23,73 | 23,73 | * | * |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| документлар әзерләү чараларын үткәрүне тәэмин итү | | | территориясендә урнашкан торак пунктларның чикләре турында белешмәләрне бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертү өчен документлар әзерләү буенча планлаштырылган чараларның гомуми күләме | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән дәүләт милке исемлегендә ел саен мөлкәт объектлары санының кимендә 10% ка артуы | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2019 – 2022 еллар | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән дәүләт милке исемлегендәге мөлкәт объектлары саны, берәмлекләр | - | - | - | - | - | - | 80 | 88 | 97 | 107 | - | - | - | - | - | 11,13 | 8,25 | 8,44 | 8,56 |
| Гомуми практика табиблары офислары өчен биналар сатып алу | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 ел | Гомуми практика табиблары офислары өчен гомуми практика табиблары офислары өчен сатып алынган биналарның гомуми саны, сатып алуга планлаштырылган гомуми практика табиблары офисларының гомуми саны, процент | - | 100 | - | - | - | - | - | - | - | | 14,21 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Бурыч: Дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы дәүләт милкен хосусыйлаштыруның фаразланган планын (программасын) үтәү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | Реформалаштырырга планлаштырылган Татарстан Республикасы предприятиеләре санында реформалаштырылган (акционерлаштыруның, бетерүнең, үзгәртеп оештыруның төгәлләнгән процедуралары белән) Татарстан Республикасы предприятиеләре өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 1,33 | 0,96 | 1,21 | 1,13 | 1,35 | 1,57 | 1,17 | 1,19 | 1,21 |
| Дәүләт катнашындагы оешмаларның устав капиталларына инвестицияләү | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | Кертү өчен планлаштырылган инвестицияләр күләменә карата дәүләт катнашында оешмаларның устав капиталларына кертелгән инвестицияләр күләме өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 671,94 | 3 009,85 | 1 539,24 | 1 104,65 | 2 916,49 | 1 190,0 | * | * | * |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр исәбеннән аларның устав фондын арттыру | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2016 – 2022 еллар | Бирү өчен планлаштырылган субсидияләр күләменә карата Татарстан Республикасы предприятиеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында бирелгән субсидияләр күләме өлеше, процент | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | 113,21 | 74,52 | 211,0 | 605,85 | * | * | * |
| Татарстан Республикасы дәүләт милкенә мөлкәт сатып алу | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт милкенә сатып алырга планлаштырылган мөлкәт күләменә карата Татарстан Республикасы дәүләт милкенә сатып алынган мөлкәт күләме өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 123,16 | 167,59 | - | 23,9 | 364,05 | 193,42 | * | * | * |
| Бурыч: Гражданнарның гамәлдәге законнарда билгеләнгән мөлкәт хокукларын тәэмин итүне оештыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасының күпбалалы гаиләләренә җир кишәрлекләрен бирү эшен оештыру* | ТР Мөлкәт министрлыгы | 2014 – 2022 еллар | Хисап елы башына җир кишәрлеген түләүсез алуга исәпкә баскан Татарстан Республикасы күпбалалы гаиләләренең гомуми санында түләүсез җир кишәрлекләре алган күпбалалы гаиләләр өлеше, процент | 81 | 93 | 75 | 75 | 72 | 71 | 71 | 69 | 69 | 69 | 4,27 | 3,04 | 3,88 | 3,59 | 4,4 | 5,03 | 3,72 | 3,8 | 3,86 |
| Программа буенча барлыгы | | | | | | | | | | | | | | 1 016,48 | 3 376,21 | 1 886,84 | 1 415,82 | 3 734,22 | 2 331,99 | 260,38 | 242,41 | 247,6 |

* Ихтыяҗ Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.